БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАЛТАЧ РАЙОН БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

«09» 02 2021 ел

**КАРАР**

№ 79

**2021 елда Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру турында**

Балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2021 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» (2020 елның 22 сентябрендәге үзгәрешләр белән) 2020 елның 5 мартындагы 158 номерлы һәм «Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары, «Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенең 2021 елның 11 гыйнварындагы 2 номерлы боерыгы белән расланган «Авыр тормыш хәлендә калган балаларның ялын оештыру» дәүләт хезмәте күрсәтү турында нигезләмә нигезендә Балтач район башкарма комитеты **карар бирә:**

1. Расларга:

- «2021 елга Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру» программасы (1 нче кушымта).

- Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру турында нигезләмә. (2 нче кушымта)

- Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмә (3 нче кушымта).

- Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия составы (4 нче кушымта).

- Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларын әзерләп бетерү һәм аларны комплекслы тикшерү буенча эш төркеме составы (5 нче кушымта).

2. Төрле милек формасындагы предприятиеләргә, оешмаларга, учреждениеләргә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру системасын саклау, сәламәтләндерү оешмаларын, төрле типтагы һәм милек рәвешләрендәге лагерьларны үстерү буенча чаралар күрергә;

тәэмин итәргә:

- 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (17 яшьне кертеп), дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балалары һәм яшьләре өчен, иҗади сәләтле актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары өчен, авыр тормыш хәлендә булган балалар өчен, профилактик исәптә торучы балалар өчен, балага айлык пособие алучы, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдәге балалар өчен шәһәр яны ял һәм сәламәтләндерү лагеренда сменалар ялын оештыруны;

- күзәтүчесез һәм тәрбиячесез балалар өчен, Эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрендә һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләрдә исәптә торучы балигъ булмаганнар өчен, Татарстан Республикасы Эчке эшләр органнары һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләр юлламасы буенча ял оешмаларында урыннар бүлеп бирүне;

- социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге иң күп санда балаларга оештырылган ял өчен шартларны;

- балаларның ял итү оешмаларында һәм оештырылган ял урыннарында балаларның иминлеген һәм сәламәтлеген, хокук тәртибен, санитар-экологик һәм янгынга каршы куркынычсызлыкны, суда куркынычсызлыкны тәэмин итүгә юнәлдерелгән санитар-эпидемиологик чаралар комплексын эшләү һәм уздыру;

- торак корпусларның, азык-төлек блокларының һәм лагерьны су белән тәэмин итү чыганакларының санитар торышына, мунча-кер юу комплексларының торышына, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасы җайланмаларының, кешеләргә янгын турында хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, янгын сүндерү чараларының булуын һәм төзеклеген, шулай ук персоналның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүен тикшерүләргә аерым игътибар итеп, сәламәтләндерү учреждениеләрен һәр сменаны ачу алдыннан аларның янгын

куркынычсызлыгы таләпләренә, санитария кагыйдәләренә, суда кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләренә, хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау шартларына һәм торышына, ял итүчеләрнең иминлегенә туры килүен тикшерү максатыннан, сәламәтләндерү учреждениеләрен комплекслы тикшерүне;

- һәр смена башланыр алдыннан аларның санитар кагыйдәләренә һәм нормаларына туры килүе турында санитар - эпидемиологик нәтиҗәләре, шулай ук Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактик эш идарәсе Кукмара һәм Балтач муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге районара бүлегенең тиешле рөхсәте булган очракта, барлык типтагы сәламәтләндерү оешмаларын ачуны;

- балаларның ял итү оешмалары тарафыннан санитар кагыйдәләрне үтәүне һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләр үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән лабораторияләр белән килешүләр төзү юлы белән санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чаралар үткәрүне;

- ял итү оешмаларына кабул ителгән балалар турында, профилактик прививкаларның милли календаре нигезендә йогышлы авыруларга каршы прививкалар ясатуның торышы турында, яшәү, тәрбияләнү, уку урыны буенча йогышлы авырулар белән элемтәләрнең булмавы турында, туберкулез диагностикасы, флюорография тикшерүе (15 яшьтән яшүсмерләргә) нәтиҗәләре турында, гельминтозларга һәм эчәк протозоаларына тикшерү, йогышлы чирләрне, шул исәптән педикулезга тикшерүләр турында медицина документларында белешмәләр булуны;

- урман-техник чаралар үткәрү (агачларның, куакларның түбән үсүче һәм коры ботакларын кисү, яшь үсенте кисү, үлән чабу, балаларның ял итү оешмалары территориясеннән коры ауган агачларны һәм чүп-чарны чыгару), дератизация һәм талпанга каршы эшкәрткән урыннарга кадәр лагерь тирәли 500 метр радиуста коры ауган агач һәм чүп-чар чыгару һәм бөтен ялны оештыру кампанисе дәвамында, кирәк булган саен;

- барлык корылмаларны, шул исәптән файдаланылмый торганнарын да, ачык территорияне, 500 метр радиуста балаларның ял итү оешмалары тирәсендәге киртәләрне 35 - 40 көн алдан һәм ачу алдыннан җиде көн алдан һәм аларны консервацияләү алдыннан дератизацион эшкәртү, шулай ук сменалар арасында һәр дератизацион эшкәртүдән соң 30 көн узгач нәтиҗәлелекне контрольдә тотуны;

- ачылу алдыннан 20-25 көн кала, балаларның ял итү оешмалары территориясен һәм аның әйләнәсендәге 50 метрлы зонаны, шулай ук талпан йогышлы энцефалиты буенча эндемик территорияләрдә урнашкан балаларның ял итү стационар оешмаларында сменалар арасында талпанга каршы эшкәртүне, талпанга каршы һәр эшкәртүдән соң өч-биш көннән

һәм 15-20 көннән соң ике тапкыр нәтиҗәлелеккә контроль үткәрүне;

- балаларның коллектив ялын оештыручылар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләр кертүне, төркемле йогышлы авырулар килеп чыгуны кисәтү максатларында, җибәрүгә кадәр кимендә өч тәүлек алдан оештырылган балалар коллективларын республика чикләренннән җибәрүнең планлаштырган вакыты турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарында территориаль бүлегенә хәбәр итүне;

- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясында каралган педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә каршылыклар булу (булмау) предметына ялны оештыруда эшкә урнашучы (эшләүче) затларны алдан тикшерүләр оештырырга;

- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балалар төркемен автобуслар белән оешкан төстә йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2013 елның 17 декабрендәге1177 номерлы карары белән расланган Балалар төркемен автобусларда йөртүне оештыру кагыйдәләре нигезендә балаларны автобусларда йөртүне оештыруны;

- балаларны сәламәтләндерү оешмалары җитәкчеләрен һәм педагогик составын хезмәтне саклау, янгын-техник минимумы программалары буенча һәм билгеләнгән тәртиптә барлык хезмәткәрләрнең гигиена әзерлеге буенча укытуны оештыруны;

- Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлык карамагындагы ял итү оешмаларына юлламалар алган балалар турында мәгълүматны социаль тәэмин итүнең бердәм дәүләт мәгълүмат системасына бирү буенча эшне;

- балалар сәламәтләндерү оешмаларын кабул итүне түләүсез уздыруны.

3. «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнә:

- гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан оештырылган көндезге ял лагерьларында укучыларның ялын оештырырга (мәктәп яны лагерьларында);

- «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагерендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештырырга;

- хезмәт һәм ял лагерьларын оештырырга.

- педагоглар составыннан балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү оешмаларының җитәкче составын килештерергә һәм билгеләргә («Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагере, көндезге ял мәктәп яны лагерьлары, гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы хезмәт һәм ял лагерьлары);

- балаларның коллектив ялын оештыручылар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләр кертүне, төркемле йогышлы авырулар килеп чыгуны кисәтү максатларында, җибәрүгә кадәр кимендә өч тәүлек алдан оештырылган балалар коллективларын республика чикләреннән җибәрүнең планлаштырган вакыты турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенең Биектау, Арча, Әтнә, Балтач районнарында территориаль бүлегенә хәбәр итәргә;

- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясында каралган педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә каршылыклар булу (булмау) предметына ялны оештыруда эшкә урнашучы (эшләүче) затларны алдан тикшерүләр оештырырга;

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән берлектә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы үткәрә торган ялны оештыручыларның квалификациясен күтәрү буенча республика курсларында лагерь җитәкчеләренең һәм тәрбия эшләре буенча урынбасарларның катнашуын тәэмин итәргә;

- сәламәтләндерү оешмаларында балаларны һәм яшьләрне бәхетсезлек очракларыннан ирекле иминләштерүне гамәлгә ашырырга;

- 2021 елда балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү оешмаларын сәламәтләндерү кампаниясенә әзерләргә һәм кабул итәргә

- практика узу чорында студентларны лагерьларда эшкә җәлеп итәргә;

- төзелгән шартнамәләр, дәүләт һәм муниципаль контрактлар нигезендә Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын файдалану турында финанс хисапларын вакытында тапшыруны тәэмин итәргә;

3. «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагере МБУ җитәкчесенә түбәндәгеләрне оештырырга:

- гамәлдәге санитария нормаларына һәм дәүләт санитар-эпидемиологик күзәтчелекне гамәлгә ашыруга вәкаләтле орган тарафыннан бирелгән кагыйдәләргә туры килүен раслаучы документ булганда, шулай ук, лагерьларның матди-техник хәлен ныгытуга юнәлтелгән план йөкләмәләренең янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен бозуларны бетерү буенча күрсәтмәләрен һәм санитария законнарын бозуларны бетерү буенча күрсәтмәләрне тулысынча үтәгәндә, «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагерен ачуны;

- балаларның ял итү оешмалары тарафыннан санитар кагыйдәләрне үтәүне һәм лаборатор-инструменталь тикшеренүләр үткәрүгә билгеләнгән тәртиптә аккредитацияләнгән лабораторияләр белән килешүләр төзү юлы белән санитария-эпидемияләргә каршы (профилактик) чаралар үткәрүне;

- 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (17 яшьне кертеп), дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, коммерциячел һәм коммерциягә карамаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балалары һәм яшьләре өчен, иҗади сәләтле актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары өчен, авыр тормыш хәлендә булган балалар өчен, профилактик исәптә торучы балалар өчен, балага айлык пособие алучы, җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдәге балалар өчен «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагеренда ял оештыруны;

- ял итү оешмаларына кабул ителгән балалар турында, профилактик прививкаларның милли календаре нигезендә йогышлы авыруларга каршы прививкалар ясатуның торышы турында, яшәү, тәрбияләнү, уку урыны буенча йогышлы авырулар белән элемтәләрнең булмавы турында, туберкулез диагностикасы, флюорография тикшерүе (15 яшьтән яшүсмерләргә) нәтиҗәләре турында, гельминтозларга һәм эчәк протозоаларына тикшерү, йогышлы чирләрне, шул исәптән педикулезга тикшерүләр турында медицина документларында белешмәләр булуын;

- балаларның коллектив ялын оештыручылар тарафыннан Татарстан Республикасы территориясенә аеруча куркыныч инфекцияләр кертүне, төркемле йогышлы авырулар килеп чыгуны кисәтү максатларында, җибәрүгә кадәр кимендә өч тәүлек алдан оештырылган балалар коллективларын республика чикләреннән җибәрүнең планлаштырган вакыты турында Кулланучылар хокукларын яклау һәм кешенең уңай тормышы өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә хәбәр итүне;

- Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 331 статьясында каралган педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнүгә каршылыклар булу (булмау) предметына ялны оештыруда эшкә урнашучы (эшләүче) затларны алдан тикшерүләр оештыруны;

- медицина персоналын эшкә алуның шартнамә формасын карауны;

- дәүләт (муниципаль) контрактлар (шартнамәләр) төзү юлы белән, әлеге төр эшләрне башкаруга хокуклы аккредитацияләнгән оешмалар белән дәүләт (муниципаль) контрактлар (шартнамәләр) төзү юлы белән талпан энцефалитын, боррелиозны һәм бөер синдромлы геморрагик бизгәкне профилактикалау максатларында, корылмаларны һәм биналарны (шул исәптән файдаланылмый торган) һәм территорияләрне профилактик дымлы дезинфекцияләүне, дезинсекцияләүне һәм дератизацияләүне;

- ачылу алдыннан 20-25 көн кала, балаларның ял итү оешмалары территориясен һәм аның әйләнәсендәге 50 метрлы зонаны, шулай ук талпан

йогышлы энцефалиты буенча эндемик территорияләрдә урнашкан балаларның ял итү стационар оешмаларында сменалар арасында талпанга каршы эшкәртүне, талпанга каршы һәр эшкәртүдән соң өч-биш көннән һәм 15-20 көннән соң ике тапкыр нәтиҗәлелеккә контроль үткәрүне.

5. Балтач муниципаль районы Кече Лызи авыл җирлеге башлыгына оештырырга:

- лагерьны ачу һәм ябу алдыннан аның әйләнәсендә 500 метр зонаны барьерлы дератизацияләү үткәрүне, лагерь янындагы территорияне алдан энтомологик бәяләү белән кимендә 50 метр арада талпанга каршы (акарицид) эшкәртүне; эшкәртүне үткәргәнче һәм үткәрелгәннән соң 30 көн узгач, дератизация эшкәртүнең нәтиҗәлелеген контрольдә тотуны.

6. Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә түбәндәгеләрне оештырырга:

- шәһәр яны ял лагерьларында, шул исәптән Кара диңгез яр буйларында, иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар өчен профильле сменаларда һәм төрле тематик юнәлештәге сменаларда балаларның һәм яшьләрнең катнашуын;

- 7 яшьтән 18 яшькә кадәрге (18 яшьне кертеп) өстәмә гомуми белем бирү программаларын үзләштерүче, иҗади сәләтле һәм социаль актив балалар өчен палатка тибындагы лагерьларның сменаларында балаларның һәм яшьләрнең, профилактик исәптә торучы балаларның, хәрби-патриотик тәрбиягә юнәлтелгән сменада катнашучыларның катнашуын;

- «Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә түбәндәгеләрне тапшыра:

- 2021 елның 1 маена кадәр барлык типтагы лагерьларны ачу графикларын;

- 2021 елның июнь аеннан декабрь аена кадәр, балаларны лагерьга кертүне гамәлгә ашырганнан соң 3 көн эчендә ай саен 25 числога кадәр оператив мәгълүматны;

- балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча йомгаклау финанс хисабын.

- балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан район бюджетына субсидияләр бирү турында ел саен килешүләр төзү эшен;

7. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлегенә:

- сәламәтләндерү лагерьларына күчмә китапханәләр эшен оештырырга;

- Балтач муниципаль районы музейларында җәйге каникуллар вакытында балаларга һәм яшүсмерләргә бушлай керү өчен атнага бер көн билгеләргә;

- сәламәтләндерү лагерьларында концертлар, дискотекалар, тематик кичәләр оештырырга.

8. Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру буенча җаваплы башкаручыга түбәндәгеләрне оештырырга:

- авыр тормыш хәлендә калган 7 яшьтән 15 яшькә кадәрге (15 яшьне кертеп) балаларның, яшүсмерләрнең балалар сәламәтләндерү лагерьларында, шифаханә-курорт учреждениеләрендә ялын һәм сәламәтләндерүен;

- авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен юлламалар бирүгә ата-аналар (яисә законлы вәкилләре) тарафыннан бирелә торган гаризаларны кабул итүне;

- Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы бүлеге һәм Балтач муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия тарафыннан бирелгән мәгълүматтан файдаланып, исемлекләрдә күрсәтелгән балаларның булуын раслау һәм ял итү оешмаларына җибәрелә торган балаларның җыелма исемлеген булдыруны.

9. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы бүлегенә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнә җан башына уртача керем яшәү минимумыннан түбәнрәк булган гаиләләрдәге балалар, социаль тернәкләндерүгә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешмаларда тәрбияләнүчеләр, социаль куркыныч хәлдә булган гаиләләрдәге балалар һәм сәламәтлеге ягыннан мөмкинлекләре чикләнгән, физик һәм (яисә) психик үсештә җитешсезлекләре булган, үз-үзен карый алмаучы балалар турында мәгълүмат бирүне.

10. Балтач муниципаль районы балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссиягә түбәндәгеләрне тапшырырга:

- балаларны сәламәтләндерү оешмаларына җибәрү турында үтенечнамәләрне һәм балаларның «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУндә исәптә булуы турында белешмәләрне.

11. «Балтач РҮХ» ДАССУсенә түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

- хроник авырулары булган 4 яшьтән 17 яшькә кадәрге, шул исәптән авыр тормыш хәлендә калган балаларның «Балалар» (озатучысыз) яки «Ана һәм бала» (ата-ананың берсе/законлы вәкил белән) юлламалары буенча шифаханәдә дәвалануын оештыруны;

- шифаханә-курорт дәвалавына мохтаҗ 30 яшькә кадәрге йөкле хатын-кызларны уздырылган медицина сайлап алуы нигезендә, шифаханәдә булу

вакытын тиешенчә кыскартып, шифаханә-курорт дәвалавына «Балалар» юлламасы буенча җибәрүне рөхсәт итүне;

- балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин ителү оешмаларын көндезге ял мәктәп яны лагерьлары, гомуми белем бирү учреждениеләре каршындагы хезмәт һәм ял лагерьлары) күрсәтелгән оешмаларны оештыручыларның заявкалары нигезендә медицина кадрлары белән комплектлауны;

- балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин ителү оешмаларын («Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагерен) контракт нигезендә, күрсәтелгән оешмаларны оештыручыларның заявкалары нигезендә медицина кадрлары белән комплектлауны;

- балигъ булмаганнарны белем алудан буш вакытта һәм каникуллар вакытында вакытлыча эшкә урнаштыруны рәсмиләштергәндә балигъ булмаганнарның медицина тикшерүләрен һәм балалар сәламәтләндерү оешмаларына эшкә җибәрелә торган персоналның сезонлы тикшерүләрен оештыруны түләүсез нигездә тәэмин итүне;

- ялны оештыру эшенә җибәрелүче персоналга сезонлы тикшерүләр кысаларында флюорография тикшерүләрен түләүсез тәэмин итүне;

- «Аларны башкарганда мәҗбүри башлангыч һәм периодик медицина карап тикшерүләре (тикшерүләр) үткәрелергә тиешле зарарлы һәм (яисә) куркыныч җитештерү факторлары һәм эшләре исемлеген һәм Зарарлы һәм (яисә) куркыныч хезмәт шартлары булган авыр эшләрдә эшләүче хезмәткәрләргә мәҗбүри башлангыч һәм периодик медицина тикшерүләре (тикшерүләр) уздыру тәртибен раслау турында» 2011 елның 12 апрелендәге 302н номерлы Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министры боерыгы таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы балаларының һәм яшьләренең ялын оештыруга бүлеп бирелә торган акчалар исәбеннән ялны оештыру эшенә юнәлтелүче персоналның түләүсез сезонлы тикшеренүләрен тәэмин итүне;

12. «Татарстан Республикасында (Татарстан) гигиена һәм эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Арча, Биектау районнарындагы филиалына түбәндәгеләрне үткәрүне түләүсез тәэмин итүне тәкъдим итәргә:

- ял итү оешмаларының гамәлдәге санитар нормаларга һәм кагыйдәләргә туры килү-килмәүгә санитар-эпидемиологик экспертизасын;

- балалар сәламәтләндерү оешмаларына эшкә җибәрелә торган персоналны гигиенага укытуны һәм профилактик медицина тикшерүләрен, ачу алдыннан лагерьларның лаборатор-инструменталь тикшеренүләрен.

13. Россия Федерациясе Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге һәм

профилактик эш идарәсенең Балтач һәм Кукмара муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге районара бүлегенә:

- балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин ителү оешмаларында янгын куркынычсызлыгы таләпләрен үтәүне күзәтүне тәэмин итәргә.

14. Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлегенә:

- Балтач муниципаль районы территориясендәге балаларның һәм яшьләрнең ял итү, сәламәтләндерү һәм эш белән тәэмин итү лагерьларында җәмәгать тәртибен, куркынычсызлыкны һәм территорияне тәүлек буе саклауны тикшереп торуны тәэмин итәргә.

15. «Балтач муниципаль районы Хуҗалык эксплуатация хезмәте» МБУнә түбәндәгеләрне оештырырга:

- урман-техник чаралар үткәрү (агачларның, куакларның түбән үсүче һәм коры ботакларын кисү, яшь үсенте кисү, үлән чабу, балаларның ял итү оешмалары территориясеннән коры ауган агачларны һәм чүп-чарны чыгару), дератизация һәм талпанга каршы эшкәрткән урыннарга кадәр лагерь тирәли 500 метр радиуста коры ауган агач һәм чүп-чар чыгару һәм бөтен ялны оештыру кампанисе дәвамында, кирәк булган саен;

16. Балтач районы буенча участок урманчысына тәкъдим итәргә:

- 123-ФЗ номерлы Федераль законның 37 статьясы нигезендә балалар сәламәтләндерү лагерен урман массивыннан аера торган янгынга каршы минераллаштырылган полосалар үткәрү.

17. Балтач муниципаль районының Финанс-бюджет палатасына:

- Программаны 2021 елга Балтач муниципаль районы бюджетында сәламәтләндерү кампаниясен оештыру чараларын финанслау өчен каралган акчалар хисабына финансларга;

- Программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын контрольдә тотарга.

18. Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагере МБУ бухгалтерына:

- түләү документларын күрсәткәннән соң, ата-аналарга яки законлы вәкилләргә «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагере МБУнә юллама бирүне оештырырга.

19. «Татмедиа» ААҖ филиалы булган «Хезмәт» газетасы редакциясенә һәм «Кайтаваз» ТРК МКУ сәламәтләндерү лагерьлары, көндезге лагерьлар, хезмәт һәм ял лагерьлары эшенең уңай тәҗрибәсен һәм бу өлкәдәге иң актуаль проблемаларны яктыртуны тәкъдим итәргә.

20. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларын әзерләп бетерү һәм аларны комплекслы тикшерү буенча эш төркеменә түбәндәгеләрне тәэмин итәргә:

- торак корпусларның, азык-төлек блокларының һәм лагерьны су белән тәэмин итү чыганакларының санитар торышына, мунча-кер юу комплексларының торышына, электр җиһазларының торышына, янгын автоматикасы җайланмаларының, кешеләргә янгын турында хәбәр итү системаларының, телефон элемтәсенең, янгын сүндерүнең беренчел чараларының булуын һәм төзеклеген, шулай ук персоналның янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләрен белүен тикшерүләргә аерым игътибар итеп, янгын куркынычсызлыгы таләпләрен, санитария кагыйдәләрен, суда кешеләрнең гомерен саклау кагыйдәләрен, хезмәткәрләрнең хезмәтен саклау шартларын һәм торышын, ял итүчеләрнең иминлеген эшләргә һәм җиткерүне;

- янгын куркынычсызлыгы кагыйдәләре таләпләренә туры килүен тикшерү максатларында, һәрбер смена ачылышы алдыннан балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларын комплекслы тикшерү оештыруны;

- «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагерен ачуны.

21. Түбәндәгеләрне билгеләргә:

- оешмалар персоналының хезмәт хакы, гамәлдәге законнарга каршы килми торган башка финанслау чыганаклары хисабына, эш бирүче тарафыннан арттырылырга мөмкин;

- Россия Федерациясе Салым кодексының 211 статьясындагы 2 пунктының 1 пунктчасы һәм 217 статьясындагы 9 пункты нигезендә барлык дәрәҗәдәге (җирле, региональ, федераль) бюджет акчалары хисабына 16 яшькә җиткән затларга, инвалидлардан тыш, бирелгән сәламәтләндерү оешмаларына юлламаларны тулысынча яисә өлешчә түләү суммасына салым салынырга тиеш.

22. Әлеге карарны pravo.tatarstan.ru «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга һәм Балтач муниципаль районының baltasi.tatarstan.ru рәсми сайтында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

23. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарына (социаль мәсьәләләр буенча) йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе
А.Ф. Хәйретдинов

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «09» 02
19 номерлы карарына
1 нче кушымта

«2021 елга Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру»

# ПРОГРАММАСЫ

Программаның паспорты

| | |
|---|---|
| Программаның исеме | «2021 елга Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру» программасы (алга таба - Программа) |
| Муниципаль заказ бирүче | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты |
| Программаны төп эшләүчеләр | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ |
| Программаның төп башкаручылары | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» муниципаль казна учреждениесе<br>Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге<br>Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы бүлеге<br>«Татарстан Республикасы Балтач районы Халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ<br>Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге<br>Россия Эчке эшләр министрлыгының Татарстан Республикасы Балтач районы буенча бүлеге<br>«Балтач район үзәк хастаханәсе» ДАССУ<br>Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Балтач һәм Кукмара муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлеге<br>Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы буенча идарәсе<br>Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Мәктәптән тыш эшләр үзәге» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе<br>Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесе<br>«Татмедиа» ААҖ филиалының Балтач районы «Хезмәт» газетасы редакциясе |

| | |
|---|---|
| Программаның максатлары һәм бурычлары | Балачакны яклау, балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру, аларның каникул вакытында мәшгульлеген тәэмин итү өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру;<br>- тормыш-көнкүрешне яхшырту һәм имин булмаган балаларның проблемаларын хәл итү;<br>- балалар һәм яшьләр ялының төрле рәвешләрен, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү;<br>- балаларның һәм яшьләрнең ял итү инфраструктурасын саклау һәм ныгыту;<br>- балалар авыруларын һәм инвалидлыкны профилактикасы;<br>- авыр тормыш хәлендәге балаларны нәтиҗәле комплекслы социаль яклауны һәм җәмгыятькә интеграцияләүне формалаштыру;<br>- балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;<br>- сәламәтләндерү учреждениеләрен персонал белән комплектлауны тәэмин итү. |
| Программаны гамәлгә ашыру вакыты һәм этаплары | 2021 елның гыйнвары-декабре |
| Программа чаралары исемлеге | 1. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге сәламәтләндерү лагерьларында сменаларны оештыру.<br>2. Гомуми белем бирү учреждениеләре укучыларының көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында сменаларны оештыру.<br>3. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары һәм коммерцияле һәм коммерциягә карамаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балалары өчен стационар лагерьларда сменаларны оештыру.<br>4. Муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары өчен стационар һәм палатка лагерьларында профильле сменалар оештыру.<br>5. Балигъ булмаганнарны вакытлыча эшкә урнаштыру. |
| Программаны финанслау күләмнәре һәм чыганаклары | 2021 елга Программаны финанслауның гомуми күләме 7034,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:<br>Татарстан Республикасы бюджеты акчалары - 6 964,1 мең сум;<br>җирле бюджет акчалары - 70,3 мең сум |

| | |
|---|---|
| Программаны гамәлгә ашыруның көтелгән соңгы нәтиҗәләре (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм аның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре | 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге балаларның гомуми санынnan 60 проценттан да ким булмаган өлешен каникул вакытында төрле ял формалары белән тәэмин итү.<br>Ял сыйфатын һәм сәламәтләндерү дәрәҗәсен күтәрү, барлык программа чаралары кысаларында чагылыш тапкан 85 процентттан да ким сәламәтләндерү эффектына ирешү. |

## 1. 2021 ЕЛДА БАЛТАЧ РАЙОНЫ БАЛАЛАРЫНЫҢ ҺӘМ ЯШЬЛӘРЕНЕҢ ЯЛЫН ОЕШТЫРУ ПРОГРАММАСЫ ЯРДӘМЕНДӘ ХӘЛ ИТЕЛӘСЕ ПРОБЛЕМАНЫҢ ХАРАКТЕРИСТИКАСЫ. 2020 ЕЛГЫ СӘЛАМӘТЛӘНДЕРҮ КАМПАНИЯСЕ НӘТИҖӘЛӘРЕ

Балачакны яклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыру, 2021 елда Балтач муниципаль районы территориясендә балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру максатларында, «2019-2025 елларга Татарстан Республикасында яшьләр сәясәтен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2020 елның 5 мартындагы 158 номерлы (2020 елның 22 сентябрендәге үзгәрешләр белән) һәм «Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру турында» 2020 елның 29 апрелендәге 346 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру буенча район ведомствоара комиссиясе Нигезләмәсе һәм 2021 елга Балтач муниципаль районы балаларының һәм яшьләренең ялын, сәламәтләндерүен, мәшгульлеген оештыру Программасы расланды.

Сәламәтләндерү кампаниясенең программа чараларын гамәлгә ашыруда 8 мәктәп яны лагере катнашты. Мәктәп яны лагерьларында 285 бала ял иткән.

Җәйге ялны оештыру барышы «Хезмәт» район газетасы битләрендә яктыртылды һәм «Кайтаваз»район радиосы аша тапшырулар оештырылды.

Балаларны һәм яшьләрне сәламәтләндерү учреждениеләрендә һәм анда барганда юлда булган вакытта ирекле иминләштерү буенча эш оештырылды.

Программаны гамәлгә ашыру нәтиҗәләре буенча гомуми мониторинг һәм анализ атна саен башкарылды.

Уңай тенденцияләргә карамастан, хәзерге вакытта балалар һәм яшьләрнең сәламәтлеген саклау һәм ныгыту мәсьәләләре актуаль булып кала бирә.

Шулай ук балалар җинаятьчелеге дә актуаль проблема булып кала.

Яшьләрне эшкә урнаштыру, аның хәзерге җәмгыятьтә социаль адаптациясе проблемасы да саклана.

Әлеге күренешләрне профилактикалау өчен сәламәтләндерү учреждениеләрендә балаларны лагерьларга җәлеп итү, профильле сменалар, мәктәп профилактика отрядлары оештыру буенча планлы һәм максатчан эш алып барыла.

Мәктәп балаларының ялын күңелле, эмоциональ яктан кызыктырырлык итеп оештыру, тормышка булган ихтыяҗларны канәгатьләндерү, иҗатта үз-үзләрен күрсәтү, хезмәт, белем, сәнгать, мәдәният, уен һәм башка мөмкин булган үз-үзеңне билгеләү өлкәләрен үз эченә алган төрле формаларда аралашу һәм үзешчән сәнгатьне үстерү өчен уңай шартлар тудырырга кирәк.

## 2. ПРОГРАММАНЫҢ МАКСАТЫ ҺӘМ ТӨП БУРЫЧЛАРЫ

Программаның максаты - балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру өчен кирәкле шартлар тудыру, аларның каникул вакытында мәшгульлеген тәэмин итү, сәламәтләндерү нәтиҗәлелеге дәрәҗәсен арттыру.

Куелган максатка ирешү түбәндәге бурычларны хәл итү юлы белән гамәлгә ашырыла:

балалар һәм яшьләр ялының төрле формаларын, балалар һәм яшьләр туризмын һәм спортны үстерү;

сәләтле балаларны, фән олимпиадаларында, иҗади конкурсларда җиңүчеләрне ачыклау, аларга ярдәм итү системасын формалаштыру;

поддержка детских и молодежных общественных организаций, волонтеров, государственная поддержка детей-сирот, детей, оставшихся без попечения родителей;

балалар авыруын һәм инвалидлыкны профилактикалау; балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалау;

авыр тормыш хәлендәге балаларны нәтиҗәле комплекслы социаль яклауны һәм җәмгыятькә интеграцияләүне формалаштыру;

мәктәп яшендәге балаларны каникул чорында ял белән тәэмин итү;

балаларны һәм яшьләрне каникуллар чорында ял белән тәэмин итү;

тормыш-көнкүреш шартларын яхшырту һәм имин булмаган балаларның проблемаларын хәл итү;

балаларны һәм яшьләрне каникуллар чорында эш белән тәэмин итү;

сәламәтләндерү учреждениеләрен персонал белән комплектлауны тәэмин итү.

## 3. ПРОГРАММАНЫ РЕСУРСЛАР БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮНЕ НИГЕЗЛӘҮ, ФИНАНСЛАУ ЧЫГАНАКЛАРЫ

2021 елга Программаны финанслауның гомуми күләме
7034,4 мең сум тәшкил итә, шул исәптән:
Татарстан Республикасы бюджеты акчалары - 6 964,1 мең сум;

җирле бюджет акчалары - 70,3 мең сум

Программа чараларын гамәлгә ашыруга бүлеп бирелә торган акчаларның максатчан кулланылышын ТР Балтач муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тикшерә.

## 4. ПРОГРАММАНЫ ГАМӘЛГӘ АШЫРУ МЕХАНИЗМЫ

2021 елда балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлегенә, «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУсына түбәндәгеләрне тапшырырга тәкъдим ителә:

«Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә: 2021 елның 1 маена кадәр - барлык төр лагерьларны ачу графигын;

2021 елның маеннан декабренә кадәр (декабрьне дә кертеп), балалар һәм яшьләр сәламәтләндерү учреждениеләренә кергәннән соң өч көнлек срокта - оператив мәгълүматны һәм ай саен 25 числога кадәр – балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру турында мониторингны;

20 августка кадәр - үткәрелгән чаралар турында фото- һәм видеоматериаллар булган иҗади хисаплар;

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгына:

2021 елның 20 апреленә кадәр - көндезге мәктәп яны лагерьларын, көндезге ял һәм хезмәт лагерьларын ачу графикларын;

2021 елның мартыннан декабренә кадәр, балалар һәм яшьләр сәламәтләндерү учреждениеләренә кергәннән соң өч көн эчендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы тарафыннан билгеләнгән формалар буенча - оператив мәгълүматны һәм ай саен 25 числога кадәр - көндезге мәктәп яны лагерьларында, көндезге ял һәм хезмәт лагерьларында балаларның ялын оештыру турында ай саен йомгаклау мәгълүматын.

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге формаларда башкарыла:

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «09» 02
79 номерлы карарына
2 нче кушымта

**Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру механизмын һәм Балтач муниципаль районы башкарма хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, дәүләт һәм дәүләтнеке булмаган учреждениеләрнең, Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруда катнашучы оешмаларның һәм гражданнарның үзара хезмәттәшлеге тәртибен билгели.

1.2. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча вәкаләтле орган булып Балтач муниципаль районы балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия тора. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча ведомствоара комиссия составы һәм нигезләмәсе Балтач район башкарма комитеты карары белән раслана.

1.3. Әлеге Нигезләмә кысаларында балаларның һәм яшьләрнең ялы дигәндә каникуллар вакытында балаларда һәм яшьләрдә шәхеснең белем һәм иҗат потенциалын үстерүне, сәламәтлекне саклауны һәм ныгытуны, авыруларны профилактикалауны, организмны чыныктыруны, сәламәт яшәү рәвеше күнекмәләрен формалаштыруны, балигъ булмаганнарның күзәтүчесезлеген һәм хокук бозуларын профилактикалауны, өлешчә яисә тулысынча Татарстан Республикасы бюджеты хисабына финанслана торган иҗтимагый файдалы һәм җитештерүчәнлек хезмәте, физик культура, спорт, туризм белән шөгыльләнүне тәэмин итә торган шартлар һәм чаралар комплексы аңлашыла.

## 2. Балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү формалары

2.1. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге формаларда башкарыла:

шәһәр читендәге ял лагерында смена;
шәһәр читендәге ял лагерында профильле смена;
белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьда смена;
хезмәт һәм ял лагерында смена;
шифаханә-курорт оешмаларында смена.

2.2. Шәһәр читендәге ял лагерында смена - каникуллар чорында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр өчен тәүлек әйләнәсе стационар базада үтүче балалар белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Җәйге каникулларда сменаның озынлыгы 21 көннән дә ким

булмаска тиеш.

2.3. Шәһәр читендәге ял лагерында профильле смена - каникуллар чорында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр өчен тәүлек әйләнәсе стационар базада үтүче иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый оешмалары активы белән ял итү һәм сәламәтләндерү эшчәнлеге формасы. Сменаның озынлыгы җәйге чорда 18 көннән ким булмаска тиеш.

2.4. Белем бирү оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьда смена - каникуллар чорында укучылар һәм тәрбияләнүчеләр өчен туклandыруны мәҗбури оештырып, көндезге вакытта күбесенчә мәгариф оешмасы базасында үтүче мәгариф оешмалары укучылары белән ял итү һәм белем бирү эшчәнлеге формасы. Сменаның дәвамлылыгы җәйге чорда 21 календарь көннән дә, көзге, кышкы һәм язгы каникулларда - җиде көннән дә ким булмаска тиеш.

2.5. Хезмәт һәм ял лагерында смена - ул каникуллар чорында туклануны түэмин итеп, көндезге вакытта күбесенчә мәгариф оешмалары базасында үтүче иҗтимагый файдалы хезмәт оештыру белән ял итү формасы. Сменаның озынлыгы-18 календарь көн.

2.6. Лагерьларда отрядлар балаларның яшен һәм мәнфәгатьләрен исәпкә алып туплана. Отрядларның саны лагерьларны булдыруга, карап тотуга һәм аның эш режимын оештыруга карата санитар-эпидемиологик таләпләр белән билгеләнгән нормативлар нигезендә билгеләнә.

## 3. Балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү кампанияләрендә катнашучылар

3.1. Ял кампанияләрендә Балтач муниципаль районы территориясендә даими яшәүче 7-18 яшьлек балалар катнаша.

3.2. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру түбәндәге категория балалар һәм яшьләр киселешендә башкарыла:

гомуми белем бирү учреждениеләре укучылары;

муниципаль һәм дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең балалары;

иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр;

республика, бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадалар җиңүчеләре һәм призерлары;

Эчке эшләр органнарының балигъ булмаганнар эшләре буенча бүлекчәләрендә һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссияләрдә ведомствоара профилактик учетта торучы балалар (алга таба-профилактик исәптә торучы балалар);

җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумы күләменнән түбәнрәк булган гаиләләрдәге балалар, шулай ук тәрбиягә алган һәм опекун гаиләләрдә тәрбияләнүче балалар;

социаль куркыныч хәлдә булган гаиләдәге балалар.

## 4. Балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү сменаларын оештыручылар

4.1. Балаларның һәм яшьләрнең ял һәм сәламәтләндерү сменаларын оештыручылар

булып Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагеры тора.

4.2. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ, Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагеры 7 яшьтән 17 яшькә кадәрге (17 яшьне кертеп), дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, коммерцияле һәм коммерциягә карамаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балалары һәм яшьләре өчен, иҗади сәләтле актив балалар һәм волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары өчен, авыр тормыш хәлендә булган балалар өчен, профилактик исәптә торучы балалар өчен ял итү һәм сәламәтләндерү лагерында сменалар, мәгариф оешмалары оештырган көндезге лагерьларда, гомуми белем бирү учреждениеләре (мәктәп яны) укучылары өчен хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар оештыручылары булып тора.

## 5. Балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыруны финанслау тәртибе

5.1. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны финанслау түбәндәге чыганаклардан башкарыла:

Татарстан Республикасы бюджеты акчалары;

ата-аналарның фаразланган акчалары;

җирле бюджет акчалары;

гамәлдәге законнарда каралган башка чыганаклар.

5.2. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслау Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә финанс чыгымнары нормативлары нигезендә Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләме чикләрендә гамәлгә ашырыла. Чираттагы финанс елына балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга финанс чыгымнары нормативлары балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру формалары киселешендә, балаларның һәм яшьләрнең ял итү кампаниясендә катнашучы бер кешегә исәпләгәндә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

5.3. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләме нормативлары, сменаларны оештыручылар һәм балаларның һәм яшьләрнең ял кампаниясендә катнашучылар киселешендә, ел саен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләмнәре нормативларын исәпләү, Балтач муниципаль районындагы халыкның демографик үзенчәлекләрен, структурасын һәм мохтаҗлыгының факттагы дәрәҗәсен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана торган Балтач муниципаль районындагы социаль хезмәтләр (инфраструктура) белән тәэмин ителешнең социаль гарантияләре дәрәҗәсе нигезендә башкарыла.

5.4. Авыр тормыш хәлендә булган балаларның, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар өчен оешмаларда тәрбияләнүчеләрнең, хроник авырулары булган балаларның, шул исәптән ата-ананың (яисә законлы вәкилләрнең) берсе

белән бергә, профилактик исәптә торучы балаларның, республика, бөтенроссия, халыкара конкурслар, ярышлар һәм олимпиадаларда җиңүчеләрнең һәм призерларның ялын оештыру Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслана.

5.5. Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән өлешләп катнашу тәртибендә түбәндәгеләрнең ял итүен оештыру финанслана:

иҗади сәләтле балаларның, волонтерларның, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзаларының, мәгариф оешмаларында тәрбияләнүчеләрнең, өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләрнең шәһәр читендәге лагерьларның профильле сменаларында ял итүен;

гомуми белем бирү оешмалары укучыларының мәгариф оешмалары оештырган лагерьларда ял итүен;

дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, коммерцияле һәм коммерциягә карамаган оешмалар (дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш) хезмәткәрләренең балаларының шәһәр яны лагерьларында ял итүен.

5.6. Балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруны Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән финанслауда өлешләп катнашу күләме түбәндәгечә:

Шәһәр читендәге лагерьда иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, белем бирү оешмаларында тәрбияләнүчеләр, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр өчен профильле смена өчен, белем бирү оешмасында сменалар өчен, мәгариф оешмасы лагерьында сменалар, федераль буйсынудагы оешмалардан тыш, дәүләт һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең балалары өчен шәһәр читендәге лагерьда сменалар өчен тиешле финанс елына балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга тоткан норматив чыгымнарның 85 проценты;

Коммерцияле һәм коммерциягә карамаган оешмаларның (федераль буйсынудагы оешмаларны да кертеп) хезмәткәрләренең балалары өчен шәһәр читендәге лагерьда смена өчен тиешле финанс елына балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга тоткан норматив чыгымнарның 42,5 проценты.

5.7. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының җирле бюджетына әлеге Нигезләмәдә күрсәтелгән нормалардан чыгып исәпләнелә торган субсидияләр бирү юлы белән балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашуны тәэмин итә. Субсидияләр бирү тиешле финанс елына Татарстан Республикасы бюджетында әлеге максатларга бүлеп бирелә торган акчалар күләме чикләрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән тәртиптә һәм шартларда гамәлгә ашырыла.

## 6. Балаларның һәм яшьләрнең ялы һәм сәламәтләндерүе өчен ата-аналар түләве күләмен билгеләү тәртибе

6.1. Сәламәтләндерү учреждениеләрендә ял иткән өчен ата-аналар түләве күләме балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыруга финанс чыгымнары нормативының кимендә 15 проценты күләмендә (барлык төр сменаларны оештырганда), ләкин юлламаның фактттагы бәясеннән 50 проценттан да артмаган күләмдә (республикакүләм профильле сменаларны оештырганда) билгеләнә.

6.2 Оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләрнең үзкыйммәтенә тигез чыгымнарны чагылдыручы юллама бәясе билгеләнә. Норматив чыгымнар реаль чыгымнарга

туры килмәсә, юлламаның факттагы бәясе һәм Татарстан Республикасы бюджетыннан бүленә торган акчаларның өлеше арасындагы аерма ата-аналар (яки законлы вәкилләр), оешмалар тарафыннан түләнә.

## 7. Мәгариф оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьда балаларның ялын оештыру тәртибе

7.1. Мәгариф оешмасы оештырган көндезге лагерьга ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы нигезендә мәгариф оешмаларында белем алучы укучылар җибәрелә.

7.2 Ата-аналар гаризасы мәгариф оешмасы директоры тарафыннан расланган форма буенча бала белем алган мәгариф оешмасына тапшырыла.

7.3 Мәгариф оешмасы ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризасы нигезендә көндезге лагерьга җибәрелә торган балалар исемлеген формалаштыра.

7.4. Исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме;

гариза биргән ата-ананың (яки законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың туган елы, ае, көне, җенесе;

ата-ананың (яки законлы вәкилнең) эш урыны;

бала белем ала торган мәгариф оешмасы исеме;

бала укый торган сыйныф.

7.5. Мәгариф оешмасы тарафыннан оештырылган көндезге лагерьларда балаларның ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан тиешле финанс елына расланган муниципаль районның балаларының һәм яшьләренең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләме нормативлары чикләрендә төзелә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

базаларында лагерьлар оештырылачак мәгариф оешмалары исемнәре;

мәгариф оешмалары киселешендә лагерьларда оештырылган урыннар саны;

мәгариф оешмалары киселешендә оештырыла торган лагерьларда сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;

балаларны базаларында лагерьлар оештырылачак мәгариф оешмалары буенча бүлү.

7.6. Мәгариф оешмасы оештырган көндезге лагерьларда балаларның ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты карары белән җәйге һәм көзге сәламәтләндерү кампанияләре өчен аерым раслана.

7.7. Өч көн эчендә Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына ял итү оешмаларына килүчеләр саны турында мәгълүмат җибәрә.

7.8 Ай саен, 25 числога кадәр, Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына, ял иткән балалар санын һәм балаларның ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, ял итүне оештыру турында мониторинг җибәрә.

7.9 Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе, Мәгариф оешмасы оештырган көндезге лагерьда ял беткәннән соң җиде көн эчендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресларына лагерьларда башкарылган эшләр турында мәгълүматны җибәрә.

## 8. Хезмәт һәм ял лагерьларында сменаны оештыру тәртибе

8.1. Хезмәт һәм ял лагерьларына иҗтимагый-файдалы хезмәткә җәлеп итү максаты белән гомуми белем бирү оешмалары укучылары җибәрелә.

Гомуми белем бирү оешмасы ата-аналар (законлы вәкилләр) гаризалары нигезендә хезмәт һәм ял лагерьларына җибәрелә торган гомуми белем бирү оешмасы балаларының исемлеген һәм хезмәт һәм ял лагерьларында аларның ялын оештыру планын формалаштыра.

8.2. Исемлектә күрсәтелә:

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме,

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

баланың туган елы, ае, көне, җенесе;

ата-ананың (законлы вәкилнең) эш урыны;

бала укый торган гомуми белем бирү оешмасы исеме;

бала укый торган сыйныф.

8.3. Хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан тиешле финанс елына расланган муниципаль районның балаларының һәм яшьләренең ялын оештыруга хезмәт күрсәтү күләме нормативлары чикләрендә төзелә һәм түбәндәгеләрне үз эченә ала:

базаларында хезмәт һәм ял лагерьлары оештырылачак гомуми белем бирү оешмаларының исеме;

мәгариф оешмалары киселешендә хезмәт һәм ял лагерьларында оештырылган урыннар саны;

мәгариф оешмалары киселешендә оештырыла торган хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар саны һәм аларның дәвамлылыгы;

балаларны базаларында хезмәт һәм ял лагерьлары оештырылачак мәгариф оешмалары буенча бүлү.

8.4. Хезмәт һәм ял лагерьларында балаларның ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты карары белән җәйге һәм көзге сәламәтләндерү кампанияләре өчен аерым раслана.

8.5. “Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе” МКУ өч көн эчендә Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына ял итү оешмаларына керүчеләрнең саны турында мәгълүмат җибәрә.

8.6. Ай саен, 25 числога кадәр, Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына, ял иткән балалар санын һәм балаларның ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, ял итүне оештыру турында мониторинг җибәрә.

8.7. Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе, хезмәт һәм ял лагерьларында сменалар тәмамланганнан соң җиде көн эчендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресларына хезмәт һәм ял лагерьларының эшчәнлеге турында мәгълүматны җибәрә.

## 9. Дәүләт һәм муниципаль оешмаларның хезмәткәрләре балаларының ялын оештыру тәртибе

9.1. Ата - аналарының берсе (яки законлы вәкиле) Балтач муниципаль районы территориясендә урнашкан муниципаль яки дәүләт оешмасы (алга таба - оешмалар)

хезмәткәре булган мәгариф оешмаларында белем алучы укучылар, ата-ана (законлы вәкил) эшли торган оешма хезмәткәрләренең вәкиллекле органына (яки бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлегенә) тапшырылган ата-аналарның (законлы вәкилнең) гаризасы нигезендә, шәһәр яны лагерьларына җибәрелә.

9.2. Оешма хезмәткәренең вәкиллекле органы (яки бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлеге) стационар лагерьларга җибәрелә торган оешма хезмәткәрләре балаларының беренчел исемлеген төзи һәм әлеге беренчел исемлекне муниципаль районның Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсенә тапшыра.

9.3. Беренчел исемлектә күрсәтелә:

Учреждение исеме;

баланың фамилиясе, исеме, атасының исеме,

гариза биргән ата-ананың (законлы вәкиленең) фамилиясе, исеме, атасының исеме;

икенче ата-анасының фамилиясе, исеме, атасының исеме (әгәр атасы да анасы да булса);

икенче ата-ананың эш урыны (әгәр булса);

баланың туган елы, ае, көне, җенесе;

бала укый торган гомуми белем бирү оешмасы исеме;

бала укый торган сыйныф;

җәйге сәламәтләндерү кампаниясе чорында баланың шәһәр читендәге лагерьда булган ае.

9.4. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ оешманың беренчел исемлеге нигезендә шәһәр читендәге лагерьларга җибәрелә торган оешма хезмәткәрләре балаларының җыелма исемлеген төзи.

9.5. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ балаларның җыелма исемлеге нигезендә шәһәр яны лагерьларында балаларның ялын оештыру планын формалаштыра, план үз эченә түбәндәгеләрне ала:

муниципаль бирем нигезендә муниципаль яки дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары җибәрелә торган муниципаль шәһәр яны лагерьларының исеме, урыннар һәм сменалар саны;

закон нигезендә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча сатып алына торган шәһәр яны лагерьларына юлламалар саны.

9.6. Муниципаль яки дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең ялын оештыру планы Балтач район башкарма комитеты карары белән раслана.

9.7. Балаларны лагерьга урнаштырганнан соң, өч көн эчендә Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре буенча министрлыгы адресына ял итү оешмаларына килүләрнең саны турында мәгълүмат җибәрә.

9.8. Ай саен, 25 числога кадәр, Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына, ял иткән балалар санын һәм балаларның ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, ял итүне оештыру буенча мониторинг җибәрә.

9.9. Балтач район башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге, шәһәр читендәге лагерьларда муниципаль яки дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары өчен оештырылган сменалар тәмамланганнан соң җиде көн эчендә, Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына шәһәр яны лагерьларында муниципаль яки дәүләт оешмалары хезмәткәрләренең балалары өчен ял оештыру турында

мәгълүмат җибәрә.

## 10. Авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын оештыру тәртибе

10.1. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән җаваплы башкаручы авыр тормыш хәлендә булган балалар өчен юлламалар бирү өчен ата-аналар (яки аларның законлы вәкилләре) тарафыннан бирелгән гаризаларны кабул итә.

10.2. Алынган гаризалар нигезендә башкарма комитетның җаваплы башкаручысы балалар исемлекләрен төзи һәм Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгының «Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә тапшыра.

10.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге ай саен «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнә җан башына уртача кереме Татарстан Республикасында билгеләнгән яшәү минимумыннан кимрәк булган гаиләләрдәге балага каралган айлык пособие билгеләнгән балалар, социаль реабилитациягә мохтаҗ балигъ булмаганнар өчен махсуслаштырылган оешмалар тәрбияләнүчеләре һәм социаль куркыныч хәлдәге гаиләләрдән булган балалар реестрын тапшыра.

10.4. Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге тарафыннан бирелгән мәгълүматтан файдаланып, җаваплы башкаручы исемлекләрдә күрсәтелгән балаларның булуын раслый һәм ял итү оешмаларына җибәрелә торган балаларның җыелма исемлеген төзи.

10.5. Авыр тормыш хәлендә булган балаларның ялын оештыру планы «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан формалаштырыла һәм республика лагерьларының исемнәре, әлеге категория балалары җибәрелә торган республика лагерьларында урыннар һәм сменалар саны, гамәлдәге закон нигезендә үткәрелә торган ачык конкурс нәтиҗәләре буенча сатып алына торган шәһәр яны лагерьларына юлламалар саны турында мәгълүматны үз эченә ала.

10.6. Балаларның ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру планы «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе»МКУ боерыгы белән раслана.

## 11. Шәһәр читендәге лагерьларның профильле сменаларында балаларның һәм яшьләрнең ялын һәм сәламәтләндерүен оештыру тәртибе

11.1. Шәһәр читендәге лагерьларның профильле сменаларында катнашу өчен республика, бөтенроссия, халыкара конкурсларда, ярышларда һәм олимпиадаларда җиңүчеләр һәм призерлар, иҗади сәләтле балалар, волонтерлар, балалар һәм яшьләр иҗтимагый берләшмәләре активы әгъзалары, мәгариф оешмалары һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләре укучылары, балаларга өстәмә белем бирү учреждениеләрендә тәрбияләнүчеләр җибәрелә.

11.2. Урта һөнәри белем бирү оешмалары укучылары шәһәр читендәге лагерьларга ата-аналарның (яки законлы вәкилләрнең) «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагеры җитәкчесе исеменә бирелгән гаризасы нигезендә җибәрелә.

11.3. Ата-аналарның гаризасы шәһәр яны лагерьларына җибәрелә торган профильле сменада катнашучы балаларның җыелма исемлеген формалаштыручы «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ тарафыннан билгеләнгән форма буенча бирелә.

11.4. Җыелма исемлектә профильле сменаның һәр катнашучысы өчен түбәндәгеләр күрсәтелә:

Баланың исеме, фамилиясе, атасының исеме;

ата-аналарның (яки законлы вәкилләрнең) фамилиясе, исеме, атасының исеме; ата-аналарның (яки законлы вәкилләрнең) эш урыны; баланың туган елы, ае, көне, җенесе;

бала укый торган мәгариф оешмасының исеме; сменада катнашучы йөри торган балаларга өстәмә белем бирү мәгариф оешмасының, иҗтимагый яшьләр оешмасының исеме (булган очракта);

баланың казанышлары яки иҗтимагый оешмалар яки берләшмәләр тәкъдимнәре исемлеге; бала укый торган сыйныф.

11.5. «Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУ профильле сменаларда катнашучы балаларның җыелма исемлеге нигезендә шәһәр читендәге лагерьларның профильле сменаларында ял итү планын формалаштыра.

11.6. Профильле сменаларда катнашучы балаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру планыбалаларның һәм яшьләрнең ялын оештыру мәсьәләсе буенча профильле сменаларны оештыру регламенты нигезендә профильле сменаларны оештыручының күрсәтмә документы белән расланa.

11.7. Профильле сменалар башланганнан соң өч көн эчендә профильле сменаларны оештыручылар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгына ял итү оешмаларына килгән кешеләр саны турында мәгълүмат җибәрә.

11.8. Ай саен, 25 числога кадәр, профильле сменаларны оештыручылар Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы адресына, ял иткән балалар санын һәм балаларның ялын оештыруга бүлеп бирелгән акчаларны күрсәтеп, ял итүне оештыру буенча мониторинг җибәрә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «09» 02
79 номерлы карарына
3 нче кушымта

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия турында
НИГЕЗЛӘМӘ

1. Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча район комиссиясе (алга таба – Комиссия) балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру максатыннан төзелде һәм Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының координация органы булып тора (алга таба-башкарма комитет).

2. Комиссия үз эшчәнлегендә гамәлдәге федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына һәм әлеге Нигезләмәгә таяна.

3. Комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

министрлыклар, төрле фондлар, акционер җәмгыятьләр, барлык милек рәвешләрендәге предприятиеләр һәм берләшмәләр, балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру һәм әзерләү буенча иҗтимагый оешмалар эшчәнлеген координацияләү;

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомстволар, оешмалар, учреждениеләр һәм предприятиеләр эшчәнлегенә анализ, комиссия утырышларында аларның эшчәнлеге турында мәгълүматны тыңлау, үз вәкаләтләре чикләрендә тәкъдимнәр һәм карарлар кабул итү, аларның үтәлешен тикшерү;

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру һәм финанслау мәсьәләләрен карау;

«Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшүсмерләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру» программасын гамәлгә ашыруны контрольдә тоту (алга таба - Программа).

4. Комиссия түбәндәгеләргә хокуклы:

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру программаларын расларга;

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр эшләү һәм аларны башкарма комитетка кертү;

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыруда катнашучы ведомстволардан, предприятиеләрдән, учреждениеләрдән аның компетенциясенә караган документларны, белешмәләрне, материалларны соратып алырга;

балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру мәсьәләләре буенча башкарма комитет карарлары үтәлешен контрольдә тотарга;

башкарма комитетка Программага үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында тәкъдимнәр кертергә.

5. Комиссия «Лето» балаларның һәм яшүсмерләрнең сәламәтләндерүен, ялын һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча республика үзәге» дәүләт бюджет учреждениесенә ай саен 25 числога кадәр программаны гамәлгә ашыруга бүлеп бирелгән акчалардан арту нәтиҗәсе белән, файдалану турында хисап тапшыра.

6. Балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру мәсьәләләре буенча кабул ителгән комиссия карарлары барлык ведомстволар, предприятиеләр, учреждениеләр тарафыннан үз компетенцияләре чикләрендә үтәлергә тиеш.

7. Комиссияне рәис җитәкли. Комиссия составына кызыксынучы ведомстволар һәм оешмалар вәкилләре керә.

Комиссия рәисе аның эшчәнлеге белән җитәкчелек итә, Комиссия утырышларын алып бара, Комиссиянең эш планын раслый. Комиссия рәисе булмаганда аның вәкаләтләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

8. Комиссия составына шулай ук Комиссия секретаре да керә. Комиссия секретаре Комиссия утырышларын әзерләү эшен оештыруны һәм Комиссия утырышларында кабул ителә торган карарларның үтәлешен мониторинглауны гамәлгә ашыра. Комиссия эшчәнлеген оештыру мәсьәләләре буенча секретарь комиссия рәисе һәм аның урынбасары йөкләмәләрен үти.

9. Комиссия үз эшчәнлеген утырышларда кабул ителә һәм комиссия рәисе тарафыннан раслана торган эш планнарына нигезендә башкара.

10. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма кварталга кимендә бер тапкыр үткәрелә. Утырышның көн тәртибен һәм аларны уздыру тәртибен Комиссия рәисе билгели.

11. Әгәр утырышта Комиссия әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, Комиссия утырышы тулы хокуклы дип санала.

12. Комиссия карарлары утырышта катнашучы затларның гади күпчелек тавышы белән кабул ителә, Комиссия рәисе кул куйган һәм үтәү өчен мәҗбүри булып торган утырыш беркетмәләре белән рәсмиләштерелә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «09» 02
79 номерлы карарына
4 нче кушымта

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ялын, сәламәтләндерүен һәм эш белән тәэмин ителүен оештыру буенча ведомствоара комиссия
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Гайнетдинов И. Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Шагаева А. Ю. | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Усманова А.О. | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты мәгариф идарәсе» МКУнең тәрбия эшләре буенча методисты, комиссия секретаре (килешү буенча). |
| Комиссия әгъзалары: | |
| Нәбиуллин Ф. Р. | Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Балтач муниципаль районы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы (килешү буенча) |
| Нургалиев А. Р. | «Балтач районы халыкны эш белән тәэмин итү үзәге» ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Яппаров Н.Г. | Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Балтач һәм Кукмара муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең өлкән инспекторы (килешү буенча); |
| Гатиятуллина А. Ф. | Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының Балтач муниципаль районындагы социаль яклау бүлеге башлыгы (килешү буенча); |
| Заһидуллин Р. Р. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; |

| | |
|---|---|
| Усманов И. К. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Балтач районы буенча бүлегенең полиция начальнигы - комиссия әгъзасы (килешү буенча); |
| Сәләхетдинова Р.Н. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының мәдәният бүлеге башлыгы вазыйфаларын башкаручы; |
| Дәүлиев Г. Д. | «Балтач район үзәк хастаханәсе» ДАССУнең баш табибы (килешү буенча). |

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитетының
2021 елның «09» 02
79 номерлы карарына
5 нче кушымта

Балтач муниципаль районында балаларның һәм яшьләрнең ял итү һәм сәламәтләндерү оешмаларын әзерләп бетерү һәм аларны комплекслы тикшерү буенча эш төркеме
СОСТАВЫ

| | |
|---|---|
| Гәйнетдинов И. Ф. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары, комиссия рәисе; |
| Шагаева А. Ю. | «Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты Мәгариф идарәсе» МКУ башлыгы; |
| Яппаров Н.Г. | Россия Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшчәнлеге идарәсенең Балтач һәм Кукмара муниципаль районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге бүлегенең өлкән инспекторы (килешү буенча); |
| Заһидуллин Р. Р. | Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының Яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы; |
| Гәниев Р.Р. | «Россия Федерациясе милли гвардия гаскәрләрен ведомстводан тыш сакның Татарстан Республикасы буенча идарәсе» федераль дәүләт казна учреждениесенең Балтач районы буенча ведомстводан тыш сак бүлеге (килешү буенча); |
| Дәүлиев Г. Д. | «Балтач район үзәк хастаханәсе» ДАССУнең баш табибы (килешү буенча); |
| Хәсәнов Р.Т. | «Татарстан Республикасы буенча Гигиена һәм Эпидемиология үзәге» федераль бюджет сәламәтлек саклау учреждениесенең Балтач районындагы филиалы баш табибы (килешү буенча); |
| | «Романтик» балалар сәламәтләндерү җәйге лагере МБУ җитәкчесе (килешү буенча). |